ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 16 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 2 – 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «социаль партнерлык органнарын» сүзләрен «хезмәт өлкәсендә социаль партнерлык органнарын (алга таба – социаль партнерлык органнары)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяда:

а) беренче өлештә «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу, күмәк сөйләшүләр алып бару, күмәк шартнамәнең, килешүләрнең проектларын әзерләү һәм аларны төзүне тәэмин итү өчен, шулай ук барлык дәрәҗәләрдәге күмәк шартнамәнең һәм килешүләрнең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итү өчен» сүзләрен «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салуны, күмәк сөйләшүләр алып баруны, күмәк шартнамәләр, килешүләр проектларын әзерләүне, күмәк шартнамәләр, килешүләр төзүне тәэмин итү өчен, шулай ук барлык дәрәҗәләрдә аларның үтәлешен тикшереп торуны оештыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күмәк сөйләшүләр алып бару, күмәк шартнамә проектын әзерләү һәм күмәк шартнамә төзү өчен локаль дәрәҗәдә комиссия төзелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 18 июль
№ 42-ТРЗ